ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 7 статьяның 3 өлешендә «яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләрен «, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү яисә муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзү, эксплуатацияләү һәм яңарту түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарыла:

1) әлеге мәгълүмат системасы операторы функцияләре тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда концессионер яисә хосусый партнер тарафыннан башкарыла;

2) концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү гамәлдә булган чорда концедент яисә хосусый партнер концессионерның яисә хосусый партнерның мондый мәгълүмат системасындагы һәм тиешле килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 58-ТРЗ